ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2021 г. Заинск № 673

**«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 620 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 9 декабрендәге 1002 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 03 февралендәге 52 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 620 номерлы

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасының 1 нче кушымтасына, 35 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:
«Сатып алына торган торак бина (шул исәптән өлешле төзелеш объекты булып торган) яисә төзелә торган торак йорт Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан булырга тиеш.».

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Р.Ф. Юнысова
7-52-84